# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында:

а) алтынчы абзацта "һәм аларга йомгак ясау" сүзләрен ", йомгаклар ясау һәм нәтиҗәләр чыгару" сүзләренә алмаштырырга;

б) сигезенче абзацта "; җирле үзидарәнең урындагы заты гражданнарның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатенә язма җавапның тәртибен һәм вакытын бозган өчен" сүзләрен төшереп калдырырга;

в) уникенче абзацта җөмлә башында "Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган" сүзләрен өстәргә;

2) 15 статьяның 1 өлешендә:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) җирлекләрнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) булдыруны һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне дә кертеп, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыру;";

б) 15 пунктта ", гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп" сүзләрен өстәргә;

в) 20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"20) җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документациясен раслау, төзүгә рөхсәтләр (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), муниципаль төзелешне, җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда объектларны файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү, җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау, муниципаль ихтыяҗлар өчен җирлек чикләрендәге җирләрне резервлау һәм җир кишәрлекләрен аерып алу, шул исәптән сатып алу юлы белән, җирлек җирләреннән файдалануга җир контролен гамәлгә ашыру;";

г) 27 пунктта ", шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру" сүзләрен өстәргә;

д) 32 пунктта "һәм күзәтчелеген" сүзләрен төшереп калдырырга;

е) түбәндәге эчтәлекле $33^1$ һәм $33^2$ пунктлар өстәргә:

"$33^1$) вәкаләтле участок полициясе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә җирлекнең хезмәт күрсәтелә торган административ участогында эшләү өчен бина бирү;

$33^2$) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр вәкаләтле участок полициясе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр күрсәтелгән вазыйфа буенча бурычларын үти торган чорга торак урыны бирү;";

ж) түбәндәге эчтәлекле 35 – 37 пунктлар өстәргә:

"35) муниципаль лотереялар уздыруга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

36) махсус икътисадый зона территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

37) җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру буенча кирәкле эшләр башкаруны тәэмин итү, ясалма җир кишәрлеген булдыру турында шартнамә төзү хокукына федераль закон нигезендә ачык аукцион үткәрү.";

3) 16 статьяның 1 өлешендә:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыру;";

б) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ һәм $8^2$ пунктлар өстәргә:

"8[1]) вәкаләтле участок полициясе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә муниципаль районның хезмәт күрсәтелә торган административ участогында эшләү өчен бина бирү;

8[2]) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр вәкаләтле участок полициясе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр күрсәтелгән вазыйфа буенча бурычларын үти торган чорга торак урыны бирү;";

в) 22 пунктта ", шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру" сүзләрен өстәргә;

г) 28 пунктта ", гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның иреклe файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп" сүзләрен өстәргә;

д) түбәндәге эчтәлекле 29 – 32 пунктлар өстәргә:

"29) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

30) муниципаль лотереялар уздыруга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

31) махсус икътисадый зона территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

32) муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру буенча кирәкле эшләр башкаруны тәэмин итү, ясалма җир кишәрлеген булдыру турында шартнамә төзү хокукына федераль закон нигезендә ачык аукцион үткәрү.";

4) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) шәһәр округы чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) төзүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне дә кертеп, шәһәр округы чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыру;";

б) түбәндәге эчтәлекле 9[1] һәм 9[2] пунктлар өстәргә:

"9[1]) вәкаләтле участок полициясе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә шәһәр округының хезмәт күрсәтелә торган административ участогында эшләү өчен бина бирү;

9[2]) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр вәкаләтле участок полициясе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр күрсәтелгән вазыйфа буенча бурычларын үти торган чорга торак урыны бирү;";

в) 26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"26) шәһәр округының генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләрен раслау, шәһәр округының генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документациясен раслау, төзүгә рөхсәтләр (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), муниципаль төзелешне, шәһәр округы территориясендә

урнашкан капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда объектларны файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү, шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау, шәһәр округы территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып бару, муниципаль ихтыяҗлар өчен шәһәр округы чикләрендәге җирләрне резервлау һәм җир кишәрлекләрен аерып алу, шул исәптән сатып алу юлы белән, шәһәр округы җирләреннән файдалануга җир контролен гамәлгә ашыру;";

г) 30 пунктта ", шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру" сүзләрен өстәргә;

д) 36 пунктта ", гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп" сүзләрен өстәргә;

е) 38 пунктта "һәм күзәтчелеген" сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) түбәндәге эчтәлекле 39 – 41 пунктлар өстәргә:

"39) муниципаль лотереялар уздыруга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

40) махсус икътисадый зона территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

41) шәһәр округы ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру буенча кирәкле эшләр башкаруны тәэмин итү, ясалма җир кишәрлеген булдыру турында шартнамә төзү хокукына федераль закон нигезендә ачык аукцион үткәрү.";

5) 20 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Гражданнарның җирле референдумда катнашу хокукларына гарантияләр, шулай ук җирле референдумны әзерләү һәм уздыру тәртибе федераль закон һәм аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.";

б) 3 өлештә "һәм аларга йомгак ясау" сүзләрен ", йомгаклар ясау һәм нәтиҗәләр чыгару" сүзләренә алмаштырырга;

6) түбәндәге эчтәлекле $22^1$ статья өстәргә:

"$22^1$ статья. **Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре**

1. Муниципаль берәмлек вәкиллекле органының сәяси партияләр (аларның региональ бүлекләре һәм башка структур бүлекчәләре) тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлекләре составында сайланган депутатлар, әлеге статьяның 6 өлешендә каралган очрактан тыш, депутат берләшмәләренә (фракцияләренә) (алга таба – фракция) керәләр. Фракциягә кандидатларның тиешле исемлеге составында сайланган барлык депутатлар (депутат) керә. Фракциягә шулай ук бермандатлы яисә күпмандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар һәм әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси партия (аның региональ

бүлеге яисә башка структур бүлекчәсе) кандидатларының исемлеге составында сайланган депутатлар (депутат) керергә мөмкин.

2. Фракцияләр эшчәнлеге тәртибе әлеге Закон, муниципаль берәмлек вәкиллекле органының регламенты йә башка акты белән билгеләнә.

3. Фракциянең тулы исеме кандидатлар исемлеге составында тиешле депутатлар сайланган сәяси партия уставында күрсәтелгән исем була. Фракция аның турындагы нигезләмәдә аның тулы исеменә туры килә торган кыскача билгеләнгән исемен булдырырга да хокуклы.

4. Фракция муниципаль берәмлек вәкиллекле органының регламентында йә башка актында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итеп теркәлергә тиеш.

Яңа теркәлгән фракция турындагы белешмәләр, шулай ук күрсәтелгән фракциягә керүче депутатлар (депутат) турындагы белешмәләр фракция теркәлгәннән соң муниципаль берәмлек вәкиллекле органының беренче утырышында игълан ителә.

5. Фракциянең эчке эшчәнлеген ул үзе аның оештыру җыелышында кандидатларның тиешле исемлеге составында сайланган депутатларның гомуми саныннан күпчелек тавыш белән фракция тарафыннан раслана торган фракция турындагы нигезләмә нигезендә мөстәкыйль оештыра.

6. Сәяси партия бетерелүгә яисә үзгәртеп корылуга бәйле рәвештә аның эшчәнлеге туктатылган очракта, муниципаль берәмлек вәкиллекле органында аның фракциясе эшчәнлеге, шулай ук бу фракциядәге депутатларның әгъзалыгы юридик затларның бердәй дәүләт реестрына тиешле язма кертелгән көннән туктатыла.

7. Сәяси партия (аның региональ бүлеге яисә башка структур бүлекчәсе) тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеге составында сайланган депутат әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә тора торган фракциядән чыгарга хокуклы түгел. Күрсәтелгән депутат бары тик үзе сайланган кандидатлар исемлеге составындагы сәяси партия әгъзасы гына булырга мөмкин.

8. Бермандатлы яисә күпмандатлы сайлау округы буенча сайланган һәм фракциягә керә торган депутат яисә әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси партиянең кандидатлар исемлеге составында сайланган һәм фракциягә керә торган депутат бары тик үзе кергән фракциянең сәяси партиясе әгъзасы гына булырга мөмкин.

9. Әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси партиянең кандидатлар исемлеге составында сайланган һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында үз фракциясе булган сәяси партиягә кергән депутат шул фракциягә керә һәм аннан чыгарга хокуклы түгел.

10. Бермандатлы яисә күпмандатлы сайлау округы буенча сайланган һәм фракциягә керә торган депутат аннан хәбәр итү тәртибендә чыгарга хокуклы.

Фракциядә депутат әгъзалыгын туктату турындагы мәгълүмат муниципаль берәмлек вәкиллекле органының әгъзалык туктатылганнан соң беренче утырышында игълан ителә.

11. Әлеге статьяның 7 – 9 өлешләрендә каралган таләпләрне үтәмәү депутат вәкаләтләрен туктатуга китерә.

12. Әгәр муниципаль берәмлек вәкиллекле органының кандидатлар исемлеге составында сайланган, фракциягә керә торган депутатларының (депутатының) вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуы бу фракция составында шундый исемлек составында сайланган депутатлар (депутат) калмауга китерсә, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында әлеге фракциянең эшчәнлеге туктатыла. Шуның белән бер үк вакытта мондый фракциядә аның составына керә торган бермандатлы яисә күпмандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатларның һәм әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси партиянең (аның региональ бүлегенең яисә башка структур бүлекчәсенең) кандидатлар исемлеге составында сайланган депутатларның әгъзалыгы туктатыла.

13. Әлеге статьяның 6, 12 өлешләре нигезендә фракция эшчәнлеген туктату турындагы мәгълүмат муниципаль берәмлек вәкиллекле органының фракция эшчәнлеге туктатылганнан соң беренче утырышында игълан ителә.

14. Бермандатлы яисә күпмандатлы сайлау округлары буенча сайланган һәм фракцияләргә кермәгән депутатлар һәм әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси партиянең (аның региональ бүлегенең яисә башка структур бүлекчәсенең) кандидатлар исемлеге составында сайланган һәм фракцияләргә кермәгән депутатлар фракцияләр булмаган депутат берләшмәләрен төзи алалар. Күрсәтелгән депутат берләшмәләре партия, территориаль, профессиональ һәм башка билге буенча төзеләләр. Мондый депутат берләшмәләренең эшчәнлек тәртибе муниципаль берәмлек вәкиллекле органының регламенты йә башка акты белән билгеләнә.

15. Муниципаль берәмлекнең бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар тарафыннан барлык депутат мандатлары биләнә торган йә әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешенең 1 пункты нигезендә төзелә торган вәкиллекле органы депутатлары фракцияләр булмаган депутат берләшмәләре төзи алалар. Күрсәтелгән депутат берләшмәләре партия, территориаль, профессиональ һәм башка билге буенча төзеләләр. Мондый депутат берләшмәләренең эшчәнлек тәртибе муниципаль берәмлек вәкиллекле органының регламенты йә башка акты белән билгеләнә.

16. Муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутаты бары тик бер депутат берләшмәсендә генә торырга хокуклы.".

**2 статья**

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 2 пунктының "е" пунктчасыннан, 3 пунктының "б" пунктчасыннан, 4 пунктының "б" пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының "е" пунктчасы, 3 пунктының "б" пунктчасы, 4 пунктының "б" пунктчасы 2012 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $22^1$ статьясындагы 1, 2, 6 – 9, 11 өлешләре нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) фракцияләргә керүче депутатларга карата һәм сайлауларда тавыш

бирү "Муниципаль органнарның һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда пропорциональ сайлау системасын куллануга бәйле рәвештә "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 35 һәм 38 статьяларына һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2011 елның 20 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көннән соң уздырылган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарындагы фракцияләргә карата кулланыла.

3. "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22$^{1}$ статьясындагы 3 – 5, 10, 12 – 16 өлешләре нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) фракцияләргә керүче депутатларга карата һәм сайлауларда тавыш бирү әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң уздырылган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарындагы фракцияләргә карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 18 ноябре
№ 89-ТРЗ